УДК 372.881.1

*Г.В. Һадиева*

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЭШЛЕКЛЕ СӨЙЛӘМ ҮРНӘКЛӘРЕ

Профессиональная коммуникация представляет собой процесс взаимодействия субъектов как носителей профессионального опыта в целях обмена информацией и одно из средств достижения цели в любой сфере деятельности. Знание татарского языка в Республике Татарстан открывает дополнительные возможности для руководителей в реализации планов и проектов. В статье представлено описание практикума для развития и совершенствования навыков применения делового татарского языка.

**Ключевые слова:** татарский язык, профессиональная коммуникация, официально-деловой стиль, ситуации делового общения, речевое поведение.

Professional communication is a process of interaction of subjects as carriers of professional experience in order to exchange information and one of the means to achieve the goal in any field of activity. Knowledge of the tatar language in the Republic of Tatarstan opens up additional opportunities for managers in the implementation of plans and projects. The article describes practicum for developing and improving skills of using business tatar language.

**Keywords:** tatar language, professional communication, official business style, business communication situations, speech behavior.

Соңгы елларда татар телен өйрәтүдә коммуникатив компетентлылык өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып санала. Актив рәвештә уку-укыту комплектлары, интенсив курслар [Петров, 2020; Шакурова, 2019], үзөйрәткечләр һәм сөйләүлекләр бастырыла, татар телен өйрәнү өчен сайтлар, кушымталар эшләнә. Нигездә, бу ресурслар мәктәпкәчә һәм башлангыч, төп, урта гомуми белем бирү, махсус һәм югары белем бирү баскычында белем алучыларга адреслана. Билгеле бер һөнәр ияләренә һәм татар телен өйрәнү һәм камилләштерү мөмкинлеге зур түгел. Әгәр дә без телгә аралашу аша өйрәтәбез икән, аны өйрәнүченең үзенчәлегеннән (һөнәре, яше һ.б.) чыгып, кызыклы аралашу темаларына корылган материал тәкъдим итәргә тиеш.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында эшләүче җитәкчеләр өчен, татар телендә эшлекле аралашуда коммуникатив күнекмәләрне камилләштерү максатыннан, уку-укыту кулланмасын эшләү аеруча мөһим. Тәкъдим ителгән хезмәт җитәкченең эшлекле аралашу күнекмәләрен үстерүгә һәм татар телен эшлекле аралашу чарасы буларак куллануга юнәлтелгән булырга тиеш.

Һөнәри эшчәнлектә җитәкче камил дәрәҗәдә сөйләм культурасына һәм эшлекле аралашуда лингвистик, коммуникатив һәм ситуациядән чыгып аралаша белү компетенцияләренә ия булырга тиеш. Эшлекле аралашу исә мәгълүмат алмашу һәм билгеле бер өлкәдә килешүгә ирешү максатларында һөнәри тәҗрибәгә ия субъектларның

үзара хезмәттәшлегеннән гыйбарәт. Татар телен белү Татарстан Республикасында һөнәри өлкәдә проект һәм планнарны тормышка ашыруда аеруча мөһим.

Җитәкче вазифасында эшләүчеләргә, татар телендә аралашу осталыгын үстерү максатыннан чыгып, «Җитәкчеләр өчен татар теле. Практикум» уку-укыту кулланмасы эшләнде. Практикум татар телендә аралашу күнекмәләрен камилләштерүгә, шулай ук, аны коммуникатив максатлардан чыгып куллануга, эшлекле һәм көндәлек аралашу ситуацияләрендә сөйләмнең нәтиҗәлеген арттыруга юнәлтелгән, бу исә тел өйрәтүдә аңлап сөйләү методын сайлау һәм эчтәлекне, тел материалын ситуатив-тематик сайлап алу аша ирешелә. Һөнәри коммуникацияләрнең эчтәлеге исә уртак эшчәнлеккә ихтыяҗ белән билгеләнә, ул үзара гамәлләрнең килешенгән булуын, анда катнашучы һәркемнең әлеге эшчәнлекнең максатларын, бурычларын һәм үзенчәлекләрен, үз ролен һәм аны гамәлгә ашыру мөмкинлекләрен аңлавын, кабул итүен күздә тота.

«Җитәкчеләр өчен татар теле. Практикум» кулланмасы татар сөйләменең рәсми-эшлекле стиль үзенчәлекләрен һәм татар телен укыту методикасының теоретик-методологик нигезләрен исәпкә алып төзелде. Хезмәт 5 бүлектән – «көн»нән тора. Һәрбер «көн» 3 блоктан тора: «Искә төшерегез», «Кабатлагыз», «Әңгәмәдә катнашыгыз». Практикум татар телен база дәрәҗәсендә белгән җитәкчеләргә адреслана.

Кулланмада тәкъдим ителгән бүлекләр бер сюжетка берләштереп бирелгән: Казанга 5 көнлек эшлекле сәфәр белән чит ил компаниясе вәкилләре килә. Сәфәрнең максаты – эшлекле сөйләшүләр алып бару, уртак предприятие төзү турында фикер алышу һәм килешүне имзалау.

«***Искә төшерегез***» бүлегендә көн темасына караган диалоглар тәкъдим ителә. Алар махсус рәвештә кыскартылып һәм адаптацияләнеп бирелә. Диалоглар эшлекле аралашу ситуациясен чагылдырган күнегүләргә нигез булып тора. Күнегүдә бирелгән җөмләләрдә кайбер сүз һәм сүзтезмәләр төшеп калган. Контекстның эчтәлегеннән чыгып, төшеп калган сүзләрне фаразларга һәм дөреслеген тикшерү өчен кулланманың ачкыч өлешеннән файдаланырга мөмкин.

*– Исәнмесез. Рәхим итегез, утырыгыз. Ничек .... ? Әйбәт кенә килдегезме? Самолетта ничек булды?*

*– Рәхмәт. ... .*

*– Ничек ял иттегез?*

*– ... .*

*– Бик кызганыч, кичә сезне ... каршы ала алмадым һәм кичке ашта да булмадым. Мин командировкада идем. ... кичә төнлә генә кайттым.*

Диалоглардан соң эчтәлекне ни дәрәҗәдә аңлауны тикшерү һәм реаль аралашуда охшаш ситуацияләргә игътибар иттерү максатыннан сораулар тәкъдим ителә. Мәсәлән, *Сез очыш өчен нинди вакыт сайлыйсыз? Ни өчен? Кайсы авиакомпанияләрне сайлыйсыз? Ни өчен?*

***«Кабатлагыз»*** бүлеге һәрбер «көн»нең лексикасын ныгытуга һәм татар грамматикасының кыен очракларын искә төшерүгә юнәлтелгән (исемнәрдә тартым категориясе, фигыль заманнары һәм юнәлешләре һ.б.) биремнәрдән тора: *Фигыльләрне укыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз: төзе – төзи, төзелә, төзешә, төзеттерә.*

Биремнәрне үтәү барышында лексик берәмлекләрне куллану күнекмәләрен үстерү, фәнни стиль, эшлекле һәм көндәлек аралашу өчен актуаль булган грамматик модельләр һәм сөйләм үрнәкләрен куллану активлаштырыла. *Сүзтезмәләрне укы, җөмләләр төзе: контракт төзү, килешүне имзалау, килешүнең проектын әзерләү, эшлекле элемтәләр булдыру.*

***«Әңгәмәдә катнашыгыз»*** бүлегендә биремнәр нигезендә, көндәлек һәм эшлекле аралашуның төрле ситуацияләреннән чыгып, сөйләмне модельләштерү ята: *Сез – компания җитәкчесе. Сезнең офиска Башкортстан делегациясе килде. Бу делегациясенең җитәкчесе белән танышыгыз. Аны үзегезнең хезмәткәрләр белән таныштырыгыз.*

*Башкортстан эшмәкәрләре белән танышыгыз. Аларның исемнәре ничек? Вазифалары нинди? Компаниядә нәрсә белән шөгыльләнәләр? Аларга үзегезнең компания турында сөйләгез.*

Сөйләм ситуацияләре диалогларның эчтәлегенә, «көн»нең лексик-грамматик материалына һәм сөйләм үрнәкләренә нигезләнә. Шулай ук, биремнәр «көн» эчендә сүз һәм гыйбарәләрне актив куллануны күз алдында тота. Биремнәрнең эчтәлеге гомуми характерда һәм ул өйрәнелгән материалны комплекслы куллануга нигезләнгән аралашу ситуацияләрен үз эченә ала. Мәсәлән, *Сез коллегагыз белән очраштыгыз. Ул сез катнашкан сөйләшүләр турында сораштыра. Аның сорауларына җавап бирегез. Сөйләшүләр ничек узды? Кайчан һәм кайда узды? Кем белән очраштыгыз? Сөйләшүләрнең максаты нинди иде? Сез нинди тәкъдимнәр ясадыгыз? Партнерлар нинди күрсәтмәләре бирде?*

Кулланмада Татарстан Республикасы, аның шәһәрләре (Казан, Алабуга һ.б.) һәм аның истәлекле урыннары (Камал театры, Тукай һәйкәле), күренекле кешеләр белән бәйле материал да урын алды. Хезмәттә шулай ук эшлекле сөйләмдә кулланырга мөмкин булган канатлы гыйбарәләр, татар халык мәкальләре дә чагылыш тапты: *Татар халык мәкальләрен укыгыз. Аларны эшлекле сөйләмдә кайчан кулланып була?*

*Өч көн кунак бул, өч көннән соң ерак бул.*
*Киеменә карап каршы алалар, акылына карап озаталар.*
*Көтеп алган кунак кадерле була.*
*Ачык ишек, якты чырай (йөз).*
*Аз сөйлә, күп тыңла.*
*Аз сөйләсәң, күп ишетерсең.*
*Башлаган эш – беткән эш.*

Практикумда тел һәм сөйләм материалы, биремнәр һәм комментарийлар татар телендә тәкъдим ителде. Материалны аңлау һәм

үзләштерү уңайлы булсын өчен, биремнәрнең аңлатмасы гадиләштерелеп бирелде. Кулланманың биремнәре башка бер арадашчы телгә мөрәҗәгать итүне күздә тотмый, чөнки ул татар телен база дәрәҗәсендә белгән җитәкчеләр өчен эшләнде. Кулланма белән төркемдә һәм мөстәкыйль эшләргә мөмкин.

«Җитәкчеләр өчен татар теле. Практикум» кулланмасы татар теленең куллану даирәсен киңәйтү һәм телне гамәли куллану дәрәҗәсен күтәрү максатыннан төзелде.

**Әдәбият**

*Петров Д.Ю.* Татарский язык. Базовый тренинг. М.: Издательство Дмитрия Петрова, 2020. 304 с.

*Шакурова М.М., Гиниятуллина Л.М.* Татарский шаг за шагом: Интенсивный курс. Казан: Магариф – Вакыт, 2019. 288 с.

*Мәкалә «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасының 3.5.4 чарасы кысаларында нәшер ителә.*

***Һадиева Гөлнара Васил кызы,***
*Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының өлкән укытучысы*